**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**
**82 нче «Көнбагышкай» катнаш төрдәге балалар бакчасы»**

# ПРОЕКТ

## «Туган телемдә дөрес сөйләшәм»

**Автор:**
**Халимова Гөлназ Гаязовна, беренче квалификацион категорияле укытучы-логопед**

**Яр Чаллы, 2022 ел**

**Кереш**

Туган телне өйрәнү мәктәпкәчә яшьтәге баланың төп шөгыльләренең берсе булып тора. Сөйләм кешегә тумыштан бирелми. Бала сөйләшә башлаганчы күп вакыт үтә. Баланың сөйләме дөрес һәм вактында үсеш алсын өчен өлкәннәр күп көч түгергә тиеш. Сөйләм культурасы - ул дөрес сөйләшә, барлык тел чараларыннан (тавыш, интонация, сүзлек запасыннан, грамматик формалардан) дөрес файдалана белү. Сөйләмнең аваз культурасын үзләштерү, сөйләмнең фонетик ягын һәм аның грамматик төзелешен коррекцияләү һәм формалаштыру, шулай ук катлаулы иҗек структурасы булган сүзләрне әйтә белү өчен беренчел әһәмияткә ия. Аваз культурасы нигезендә, аваз анализы, сүз һәм сүзләрне укырга өйрәтү, димәк, грамотага өйрәтү булачак.

Кызганычка каршы, елдан-ел сөйләм культурасы бозылган, сөйләмнең фонетик ягын һәм аның грамматик төзелешен коррекцияләүдә һәм формалаштыруда ярдәм таләп ителгән балаларның артуы күзәтелә. Яр Чаллы шәһәренең 82нче санлы "Көнбагышкай" балалар бакчасында 3 логопед төркеме эшли: 1 төркем фонематик ишетү өлкәсендә, 2 төркем гомуми сөйләм үсеше өлкәсендә коррекция таләп ителгән балалар өчен. Бакчада белем һәм тәрбия бирү балаларның туган (татар) телендә оештырыла. Ләкин балалар бакчаларында эшләүче укытучы - логопедлар өчен татар телендә методик әсбапларның чикләнгән булуы, дөресрәге булмавы, балаларның татар телендә грамоталы, дөрес сөйләмен формалаштыруда авырлыклар тудыра. Әлеге **проблеманы** чишүне күздә тотып, беренче квалификацион категорияле укытучы-логопед Халимова Гөлназ Гаяз кызы озак вакытлы «Туган телемдә дөрес сөйләшәм» проекты эшләде.

Инновацион методлар кулланып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телләрендә иркәле дөрес сөйләм культурасын камилләштерү **проектның яңалыгы** булып тора.

**Практик әһәмияте:** әлеге проектны балаларның туган телдә дөрес сөйләмен үстергәндә яки балаларның сөйләмендә булган кимчелекләрне төзәтү вакытында кулланырга мөмкин.

**Проектның максаты:** мәктәпкәчә белем бирү шартларында инновацион методлар кулланып балаларның туган телдә дөрес сөйләм культурасын үстерү өчен шартлар тудыру.

**Проектның бурычлары:**

- Педагогик практикада балаларның туган телдә дөрес сөйләм культурасын үстерүне тәэмин итүче авторлык методик кулланмалар һәм заманча уен технологияләре куллануны системалаштыру.

- Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы шартларында туган телендә иркен һәм дөрес аралашучы шәхес формалаштыру өчен заманча үстерелешле мохит булдыру.

- Балаларның туган (татар) телендә аваз әйтәлешен коррекцияләү һәм дөрес формалаштыруда педагогларның методик компетентлыгын үстерү өчен шартлар тудыру.

- Балаларның туган (татар) телендә аваз әйтәлешен коррекцияләү һәм дөрес формалаштыруда педагогларның һәм ата-аналарның көчләрен берләштерү, ата-аналар потенциалын киң куллану.

**Белем өлкәләрен интеграцияләү:** «Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып-белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгать-эстетик үсеш», «Физик үсеш».

**Проектның катнашучылары:** сөйләмнәрендә кимчелекләр булган зурлар төркемендә тәрбияләнүчеләр (5-6 яшь), тәрбиячеләр, ата-аналар, укытучы-логопед.

**Методик тәэмин ителү:** Р.К. Шәехова «Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы», Ф.В.Хазратова, З.Г.Шәрәфетдинова, И.З.Хәбибуллина «Туган телдә сөйләшәбез», З.М.Зарипова «Говорим по-татарски» (өлешчә) укыту-методик комплектлар, С. Әхмәтов «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да», К.В. Закирова «Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак», К.В. Закирова «Балачак аланы», К.В.Закирова «Әхлак нигезе – матур гадәт», Н.Исәнбәт «Балалар фольклоры», М.Ф. Кашапова «Иң татлы тел-туган тел», М.Ф. Кашапова «Уйныйк әле балалар», Р.Ягфаров «Татар балалар фольклоры», Р. Ягъфәров «Татар халык уеннары», Р.Ягъфәров «Ал кирәк, гөл кирәк», Р. Ягъфәров «Алтын кашык», Р. Ягъфәров «Кәҗә-мәкәрҗә», Г.В.Чиркина, Т.Б. Филичева «Технология логопедического обследования», Г.В. Чиркина «Программы дошкольных образовательных учреждений компенсирующего вида для детей с нарушениями речи», Т.Б. Филичева, Н.А. Чевелева, Г.В. Чиркина «Нарушения речи у детей: Пособие для воспитателей дошкольных учреждений».

**Техник чаралар:** проектор, интерактив такта, компьютер, видеокамера, компьютер, принтер, ламинатор, брошюратор.

**Социаль партнерлар:** ФГБОУ ВО «НГПУ», МБУ «ЦПМСС №85».

«Туган телемдә дөрес сөйләшәм» проекты – **озак вакытлы** (2021нче елның августыннан 2022нче елның маена кадәр).

**Проектны тормышка ашыру этаплары.**

I. Әзерлек этабы. (август 2021 ел)

Проектны тормышка ашыру шартларын тикшерү.

Проблеманың торышына теоритик анализ ясау.

Яңа технологияләр белән танышу.

Диагностика өчен инструментлар әзерләү.

II. Проектны тормышка ашыру этабы. (сентябрь 2021 ел – май 2022 ел)

Инновацион укыту методлары нигезендә балаларның туган (татар) телендә дөрес сөйләм культурасын формалаштыру.

Балаларның туган (татар) телендә дөрес сөйләм культурасын формалаштыру өчен интерактив, инновацион методик әсбаплар әзерләү.

III. Йомгаклау этабы. (май 2022 ел)

Балаларның белемнәрен һәм осталыкларын бәяләү юлы белән, туган телдә дөрес сөйләм культурасын үстерү буенча, проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген анализлау.

Проект кысаларында әзерләнгән методик кулланмаларны туплау һәм трансляцияләү.

**Проектны тормышка ашыру ысуллары.**

Практик:

-дидактик, сүзле, интерактив уеннар,

-сулыш күнегүләре,

-образлы физкультура паузалары.

Күрсәтмәле:

-иллюстрацияләр, рәсемнәр күрсәтү, видеороликлар карау,

-дөрес әйтү үрнәге.

Сүзле:

-сөйләм аппаратын үстерүгә күнегүләр,

-хикәяләр, мәкальләр һәм әйтемнәр уку,

-дөрес әйтү үрнәге.

Проектны тормышка ашыруда туган телендә иркен һәм дөрес аралашу өчен заманча үстерелешле мохит булдыру зур роль уйный. Аны тулыландыруда ата-аналар һәм төркем тәрбиячеләре актив катнаша. Төркемнең барлык киңлеге балаларның сөйләм үсешен камилләштерү эшчәнлегендә актив кулланылуга карамастан, сөйләм үзәге дә оештырылган.

Мәктәпкәчә учреждениедә иркен логопед кабинеты бар. Ул мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телдә сөйләм эшчәнлеген активлаштыру өчен уен мәйданчыгы булып тора. Кабинет заманча әсбаплар, интерактив техника белән җиһазландырылган.

Әлеге проект эшчәнлеге өч **юнәлеш**тән тора: педагоглар, балалар һәм ата-аналар белән эш.

Авторлык остаханәсе кысаларында укытучы-логопед Халимова Г.Г. балаларның туган телдә дөрес сөйләм культурасын үстерү өчен шартлар тудыру өстендә педагогик эш алып бара. Татар балалар бакчаларында логопед төркемнәрендә коррекция эшен алып бару өчен методик әсбапларның чикләнгән булуын күз алдында тотып, проектны тормышка ашыру дәверендә методик кулланмалар әзерләү планлаштырылды:

- Логопедлар һәм логопед төркеме тәрбиячеләре өчен татар телендә авторлык дидактик һәм интерактив уеннар әзерләү.

- Логопедлар һәм логопед төркеме тәрбиячеләре өчен татар телендә авазларны дөрес әйтергә һәм грамотага өйрәтергә ярдәм итүче методик кулланма әзерләү.

- 4-7 яшьлек балаларның сүзлек запасын һәм фикерләү сәләтен үстерү өчен татар телендә эш дәфтәрләре әзерләү.

Балалар белән эш вактыныда иң беренче мониторинг үткәрү һәм мониторинг нәтиҗәләренә таянып коррекция эшен алып бару күздә тотыла. Шәһәркүләм һәм региональ олимпиада, тематик конкурсларда катнашып, тәҗрибә уртаклашу эше дә планлаштырылган.

Гаилә һәм мәктәпкәчә учреждение-ике тәрбия феномены, аларның һәрберсе үз урынында балага социаль тәҗрибә бирә. Тик бер-берсе белән бергә үрелеп эшләгәндә генә алар кечкенә кешенең зур дөньяга җайлашуы өчен оптималь шартлар тудыра ала. Яңа технологияләр куллану ата-аналар белән заманча хезмәттәшлек итү өчен киң мөмкинлекләр ача.

Проектны тормышка ашыру буенча ата-аналар белән эшне планлаштыру шәхси әңгәмәләр һәм консультацияләр белән башланып китте. Тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен анализлап, күп кенә ата-аналарның балаларында туган телдә дөрес сөйләм культурасын формалаштыруга битараф булганлыгы ачыкланды. проблеманы аңлап ата-аналар безнең фикерне хупладылар. Проектны тормышка ашыруда теләп катнашачакларын белдерделәр. Проект кысаларында ата-аналар белән түбәндәге эшләр планлаштырылган: индивидуль консультацияләр, видеоконференция «Өй шартларында туган телдә сөйләм мохите булдыру», «Гаилә учагы» ата-аналар кафедрасы эшчәнлеге, «Сораулар һәм җаваплар кичәсе» һәм башкалар.

Балалар һәм ата-аналар проектта зур кызыксыну белән катнашалар, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телдә дөрес сөйләм культурасын формалаштыру эшчәнлеге буенча үз тәкъдимнәрен кертәләр.

**Педагоглар белән эш**

| Тема һәм эчтәлек | Эш форма | Вакыты | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| Проблеманы өйрәнү | Авторлык остаханәсе (Авторская мастерская) | август 2021 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г. |
| Баланың шәхси үзенчәлекләрен һәм үсеш перспективаларын | Мониторинг | сентябрь 2021 ел, гыйнвар, май 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ачыклау | | | тәрбяләнүчеләр |
| Балаларның татар телендә грамоталы, дөрес сөйләмен формалаштыру | Коррекция эше алып бару | сентябрь 2021 ел – май 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр |
| «Өй шартларында туган телдә сөйләм мохите булдыру» | Видеоконференцсвязь (Zoom) | октябрь 2021 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, ата-аналар |
| «Гаилә учагы» ата-аналар кафедрасы «Матур һәм дөрес сүз көндәлеге» | Иҗади остаханә | ноябрь 2021 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, ата-аналар, ПМПК белгечләре |
| Логопедлар һәм логопед төркеме тәрбиячеләре өчен татар телендә авторлык дидактик һәм интерактив уеннар әзерләү | Авторлык остаханәсе (Авторская мастерская) | сентябрь 2021 ел – гыйнвар 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г. |
| Логопедлар һәм логопед төркеме тәрбиячеләре өчен татар телендә авазларны дөрес әйтергә һәм грамотага өйрәтергә ярдәм итүче методик кулланма әзерләү | Авторлык остаханәсе (Авторская мастерская) | ноябрь 2021 ел – апрель 2022 ел | Укытучы-логопедлар: Халимова Г.Г., Тухбатуллина Г.Г., Миндиярова Г.Р. |
| «Сораулар һәм җаваплар кичәсе» | Әңгәмә | декабрь 2021 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, ата-аналар |
| «Инновацион технологияләрне гамәлгә кертү шартларында мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән укытучы-логопед эшен оештыру» | Региональ семинар | февраль 2022 ел | Мөдир, өлкән тәрбияче, укытучы логопедлар, логопед төркеме тәрбиячеләре |
| «Белем җәүһәрләре» | Региональ олимпиада | февраль 2022 ел | Мөдир, өлкән тәрбияче, укытучы логопедлар, логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | ата-аналар, НГПУ педагоглары |
| «Туган телем-минем байлыгым» («Родной язык – мое богатство») | Шәһәр конкурсы | февраль – март 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, ата-аналар |
| 4-5 яшьлек балаларның сүзлек запасын һәм фикерләү сәләтен үстерү өчен татар телендә эш дәфтәрләре әзерләү | Авторлык остаханәсе (Авторская мастерская) | февраль 2022 ел | Укытучы-логопедлар: Халимова Г.Г., Тухбатуллина Г.Г., Миндиярова Г.Р. |
| 5-6 яшьлек балаларның сүзлек запасын һәм фикерләү сәләтен үстерү өчен татар телендә эш дәфтәрләре әзерләү | Авторлык остаханәсе (Авторская мастерская) | март 2022 ел | Укытучы-логопедлар: Халимова Г.Г., Тухбатуллина Г.Г., Миндиярова Г.Р. |
| 6-7 яшьлек балаларның сүзлек запасын һәм фикерләү сәләтен үстерү өчен татар телендә эш дәфтәрләре әзерләү | Авторлык остаханәсе (Авторская мастерская) | апрель 2022 ел | Укытучы-логопедлар: Халимова Г.Г., Тухбатуллина Г.Г., Миндиярова Г.Р. |
| «Тукай безнең йөрәкләрдә». | Шәһәр нәфис сүз конкурсы | апрель 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, әти-әниләр |
| Методик портфель әзерләү | Авторлык остаханәсе (Авторская мастерская) | май 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г. |

**Балалар белән эш**

| Тема һәм эчтәлек | Эш форма | Вакыты | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| Баланың шәхси үзенчәлекләрен һәм үсеш перспективаларын ачыклау | Мониторинг | сентябрь 2021 ел, гыйнвар, май 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр. |
| Балаларның татар телендә грамоталы, дөрес сөйләмен формалаштыру | Коррекция эше алып бару | сентябрь 2021 ел – май 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр |
| «Белем җәүһәрләре» | Региональ олимпиада | февраль 2022 ел | Мөдир, өлкән тәрбияче, укытучы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | логопедлар, логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, ата-аналар, НГПУ педагоглары |
| «Туган телем-минем байлыгым» («Родной язык – мое богатство») | Шәһәр конкурсы | февраль – март 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, ата-аналар |
| «Тукай безнең йөрәкләрдә». | Шәһәр нәфис сүз конкурсы | апрель 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, ата-аналар |

**Ата-аналар белән эш**

| Тема һәм эчтәлек | Эш форма | Вакыты | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| Мониторинг нәтиҗәләре белән таныштыру | Индивидуль консультацияләр | сентябрь 2021 ел, гыйнвар, май 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., ата-аналар |
| «Өй шартларында туган телдә сөйләм мохите булдыру» | Видеоконференцсвязь (Zoom) | октябрь 2021 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, ата-аналар |
| «Гаилә учагы» ата-аналар кафедрасы «Матур һәм дөрес сүз көндәлеге» | Иҗади остаханә | ноябрь 2021 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, ата-аналар, ПМПК белгечләре |
| «Сораулар һәм җаваплар кичәсе» | Әңгәмә | декабрь 2021 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, ата-аналар |
| «Белем җәүһәрләре» | Региональ олимпиада | февраль 2022 ел | Мөдир, өлкән тәрбияче, укытучы логопедлар, логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, ата-аналар, НГПУ педагоглары |
| «Туган телем-минем байлыгым» («Родной язык – мое | Шәһәр конкурсы | февраль – март 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме |

| | | | |
|---|---|---|---|
| богатство») | | | тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, ата-аналар |
| «Тукай безнең йөрәкләрдә». | Шәһәр нәфис сүз конкурсы | апрель 2022 ел | Укытучы-логопед Халимова Г.Г., логопед төркеме тәрбиячеләре, тәрбияләнүчеләр, ата-аналар |

**Проектны бәяләү**

Үсеш дәрәҗәсен бәяләү индивидуаль һәм фронталь тикшеренүләр һәм әңгәмәләр формасында үткәрелә.

Диагностик картада дүрт күрсәткечтән торган материаллар тәкъдим ителгән.

| Күрсәткечләр | Дәрәҗәләр | Баллар |
|---|---|---|
| **Авазларны ишетә һәм аера белү, дөрес әйтү культурасы.** | Фонематик ишетү – бар авазларны да дөрес дифференцацияли (аера). Артикуляцион моторика - барлык хәрәкәтләр дә тулысынча башкарыла. Аваз әйтелеше – бала бар авазларны да әйтә. Сөйләмнең гомуми яңгырашы - бала текстны әйтеп бирә ала, тавыш көчен һәм сөйләм темпын җайга сала ала. | 3 балл |
| | Фонематик ишетү – хаталар җибәрә, тик аларны мөстәкыйль дөресли ала. Артикуляцион моторика - барлык хәрәкәтләр акрын һәм киеренке башкарыла. Аваз әйтелеше – әйтелеше катлаулы булган авазларны әйтми. Сөйләмнең гомуми яңгырашы - бала текстны аңлаешлы әйтми, тавыш көчен һәм сөйләм темпын җайга төгәл салмый. | 2 балл |
| | Фонематик ишетү – хаталар җибәрә, аларны педагог ярдәме белән дөресли. Артикуляцион моторика – телнең торыш урынын озак эзли, тулы булмаган хәрәкәтләр башкарыла. Аваз әйтелеше – күп авазларны әйтми. Сөйләмнең гомуми яңгырашы - бала текстны аңлаешы әйтми, тавыш көчен һәм сөйләм темпын җайламый. Баланың сөләме гомумән аңлашылмый. | 1 балл |
| **Сүз байлыгы (актив һәм пассив сүзлек).** | Сүз байлыгы зур. Сузләрнең мәгънәсен аңлап, бәйләнешле сөйләмдә урынлы куллана. Туган телендә (татарча) гына сөйләшә ала. | 3 балл |
| | Сүз байлыгы уртача. Сузләрнең мәгънәсен аңлый, бәйләнешле сөйләмдә авырлык белән куллана. Сөйләшкәндә рус телендә дә сүзләр әйтергә мөмкин. | 2 балл |
| | Сүз байлыгы сай. Сузләрнең мәгънәсен аңлый, бәйләнешле сөйләмдә куллана алмый. Сөйләшкәндә күбрәк рус телендә сүзләр куллана. | 1 балл |
| **Грамматик күнекмәләр** | Сөйләмдә төрле синтаксик конструкцияләрне дөрес куллана белә; фигыльлләрне исемнәр | 3 балл |

| | | |
|---|---|---|
| **формалашуы** | белән яраклаштыра, исемнәрне килешләрдә, берлек һәм күплек санда төрләндерә; ясалма сүзләр төзи, тамырдаш сүзләрне таба белә. Аерым авыр очракларда гына хаталар җибәрә. | |
| | Сөйләмдә төрле синтаксик конструкцияләрне авырлык белән куллана; фигыльләрне исемнәр белән яраклаштыра, исемнәрне килешләрдә, берлек һәм күплек санда авырлык белән төрләндерә; ясалма сүзләр төзүдә, тамырдаш сүзләрне табуда хаталар ясый. Катлаулы җөмләләр төзегәндә хаталар җибәрә. | 2 балл |
| | Сөйләмдә төрле синтаксик конструкцияләрне кулланмый; фигыльләрне исемнәр белән яраклаштыра, исемнәрне килешләрдә, берлек һәм күплек санда төрләндерә алмый; ясалма сүзләр төзи алмый, тамырдаш сүзләрне тапмый. Гади җөмләләр генә төзи. | 1 балл |
| **Туган телне (татар телен) белү** | Бала көнкүрештәге предметларны һәм гамәлләрне билгеләүче сүзләрне белә. Туган телендә сорауларга җавап бирә белә. | 3 балл |
| | Бала көнкүрештәге предметларны һәм гамәлләрне билгеләүче сүзләрне белә. Туган телендә сорауларга авырлык белән җавап бирә белә. | 2 балл |
| | Бала көнкүрештәге предметларны һәм гамәлләрне билгеләүче сүзләрне белә. Туган телендә сорауларга авырлык белән җавап бирә алмый. | 1 балл |

**Мониторинг нәтиҗәләре әлеге таблицага тутырыла**

| № | Балалар исемлеге | Күрсәткечләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | **Гомуми бәя** | **Үсеш дәрәҗәсе** |
| **1** | | | | | | | |
| **2** | | | | | | | |
| **3** | | | | | | | |
| **4** | | | | | | | |

Баланың үсеш дәрәҗәсе төп күрсәткечләрнең суммасын гомуми күрсәткечләр санына (4кә) бүлеп билгеләнә.

Бала үсешенең йомгаклау күрсәткече түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\text{Үсеш дәрәҗәсе} = \frac{1+2+3+4}{4}$$

**Бәяләүнең якынча нормалары (балларда)**

| Дәрәҗәләр | Йомгаклау күрсәткечләре (балларда) |
|---|---|
| Югары | 2,6-3 |

| | |
|---|---|
| Уртача | 1,6-2,5 |
| Түбән | 1-1,5 |

**Дәрәҗәләрне тасвирлау характеристикасы**

**III (югары) дәрәҗә – 2,6-3 балл.**

Фонематик ишетү – бар авазларны да дөрес дифференцацияли (аера). Артикуляцион моторика - барлык хәрәкәтләр дә тулысынча башкарыла. Аваз әйтелеше – бала бар авазларны да әйтә. Сөйләмнең гомуми яңгырашы - бала текстны әйтеп бирә ала, тавыш көчен һәм сөйләм темпын җайга сала ала.

Сүз байлыгы зур. Сузләрнең мәгънәсен аңлап, бәйләнешле сөйләмдә урынлы куллана. Туган телендә (татарча) гына сөйләшә ала.

Сөйләмдә төрле синтаксик конструкцияләрне дөрес куллана белә; фигыльлләрне исемнәр белән яраклаштыра, исемнәрне килешләрдә, берлек һәм күплек санда төрләндерә; ясалма сүзләр төзи, тамырдаш сүзләрне таба белә. Аерым авыр очракларда гына хаталар җибәрә.

Бала көнкүрештәге предметларны һәм гамәлләрне билгеләүче сүзләрне белә. Туган телендә сорауларга җавап бирә белә.

**II (уртача) дәрәҗә – 1,6-2,5 балл**

Фонематик ишетү – хаталар җибәрә, тик аларны мөстәкыйль дөресли ала. Артикуляцион моторика - барлык хәрәкәтләр акрын һәм киеренке башкарыла. Аваз әйтелеше – әйтелеше катлаулы булган авазларны әйтми. Сөйләмнең гомуми яңгырашы - бала текстны аңлаешлы әйтми, тавыш көчен һәм сөйләм темпын җайга төгәл салмый.

Сүз байлыгы уртача. Сузләрнең мәгънәсен аңлый, бәйләнешле сөйләмдә авырлык белән куллана. Сөйләшкәндә рус телендә дә сүзләр әйтергә мөмкин.

Сөйләмдә төрле синтаксик конструкцияләрне авырлык белән куллана; фигыльләрне исемнәр белән яраклаштыра, исемнәрне килешләрдә, берлек һәм күплек санда авырлык белән төрләндерә; ясалма сүзләр төзүдә, тамырдаш сүзләрне табуда хаталар ясый. Катлаулы җөмләләр төзегәндә хаталар җибәрә.

Бала көнкүрештәге предметларны һәм гамәлләрне билгеләүче сүзләрне белә. Туган телендә сорауларга авырлык белән җавап бирә белә.

**I (түбән) дәрәҗә - 1, 3-2, 3 балл**

Фонематик ишетү – хаталар җибәрә, аларны педагог ярдәме белән дөресли. Артикуляцион моторика – телнең торыш урынын озак эзли, тулы булмаган хәрәкәтләр башкарыла. Аваз әйтелеше – күп авазларны әйтми. Сөйләмнең гомуми яңгырашы - бала текстны аңлаешы әйтми, тавыш көчен һәм сөйләм темпын ңайламый. Баланың сөләме гомумән аңлашылмый.

Сүз байлыгы сай. Сузләрнең мәгънәсен аңлый, бәйләнешле сөйләмдә куллана алмый. Сөйләшкәндә күбрәк рус телендә сүзләр куллана.

Сөйләмдә төрле синтаксик конструкцияләрне кулланмый; фигыльләрне исемнәр белән яраклаштыра, исемнәрне килешләрдә, берлек һәм күплек санда төрләндерә алмый; ясалма сүзләр төзи алмый, тамырдаш сүзләрне тапмый. Гади җөмләләр генә төзи.

Бала көнкүрештәге предметларны һәм гамәлләрне билгеләүче сүзләрне белә. Туган телендә сорауларга авырлык белән җавап бирә алмый.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

Педагоглар өчен:

- Проект өстендә эшләү өчен кирәкле методик әсбаплар, материаллар әзерләнә һәм туплана.
- Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары (6-7 яшь) белән эшне дәвам итү өчен яңа проект әзерләнә.

Балалар өчен:

- Балаларда туган телдә грамоталы сөйләшә белү, сөйләм культурасын үстерү өчен барлык тел чараларыннан да файдалана белүгә кызыксыну барлыкка килә.
- Балалар сөйләм ритмын, сөйләм сулышын дөрес кулланырга өйрәнәләр.
- Балаларда сүзне дөрес ишетә һәм кабатлый белү, аның яңгырашын дөрес итеп әйтеп бирә белү сәләте үсә.

Ата-аналар өчен:


- Ата-аналарда үзләренең һәм балаларының туган телдә грамоталы сөйләшә белүе, сөйләм культурасын үстерүе өчен барлык тел чараларыннан да файдалана белүенә кызыксыну барлыкка килә.

**Проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген билгеләү**

Инновацион технологияләр ярдәмендә сүзлек запасын тулыландыру, сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, тавыш ягын үстерүдәге кимчелекләрне тулыландыру, туган телдә сөйләм культурасын формалаштыру кебек бурычлар хәл ителде. Балаларның белем алу процессы белән кызыксынуы артты, мөстәкыйль эш һәм үз-үзеңне тикшерү күнекмәләре барлыкка килде.

Әлеге проект уеннар һәм күнегүләр ярдәмендә сөйләм культурасын үстерү бурычларын хәл итүгә комплекслы якын килүе һәм туган телдә сөйләм культурасын формалаштыру буенча яңа уен технологияләрен куллануы белән кызыклы. Сөйләмнең аваз культурасын үстерүгә юнәлтелгән методларны һәм чараларны кулланып әзерләнгән

барлык материаллар, методик әсбаплар, уеннар һәм күнегүләр «Педагогик портфель»гә тупланган (логопед төркемнәрендә эшләүче укытучы-логопедлар һәм тәрбиячеләр өчен методик кулланмалар, интерактив уеннар җыентыгы, Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә 4-7 яшьлек балаларның актив сүзлеген һәм фикерләвен үстерү буенча, индивидуаль һәм төркемнәрдә эшләү өчен эш дәфтәрләре һ.б.), бу ел дәвамында уен эшчәнлегенең төрле төрләрен кызыксыну белән оештырырга мөмкинлек бирә. Шулай ук тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән тәрбия-белем бирү эшчәнлегенең бердәмлеген дә билгеләп үтәргә кирәк. Укытучы-логопед тарафыннан кабат тикшерү нәтиҗәләре буенча мәктәпкәчә яштәге балаларның сөйләм культурасының үсеш дәрәҗәсенә анализ ясалды.




Мониторинг күрсәткечләрен чагыштыру уңай нәтиҗә күрсәтә. Балалар дөрес төгәл сөйләмгә ия булдылар, сәнгатьле сөйләмнең төрле чараларын куллана беләләр, бу аларның уңышлы аралашуы, социаль элемтәләр урнаштыра алуы һәм бала шәхес булып формалашуы өчен яхшы нигез булып тора.

Шулай итеп, «Туган телемдә дөрес сөйләшәм» проекты кысаларында инновацион уен технологияләрен, метод һәм алымнарны куллану, сөйләм үсеше мохите булдыру балаларның туган (татар) телдә грамматик сөйләм культурасына карата кызыксынуларын үстерүгә мөмкинлек бирәчәк.

***Список использованной литературы.***

Әхмәтов С. Уйныйбыз да, җырлыйбыз да. – Набережные Челны, 1991.

Закирова К.В. Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак - Казань, 2012.

Закирова К.В. Балачак аланы. – Казань, 2011.

Закирова К.В. Әхлак нигезе – матур гадәт. - Казань, 2004.

Закирова К.В. Иң матур сүз. – Казань, 2000.

Закирова К.В. Күңел ачыйк бергәләп. – Казан, 2003

Закирова К.В. Күңел ачыйк әле бергәләп. – Казань,2003.

Закирова К.В. Уйный-уйный үсәбез. – Казань, 2005

Закирова К.В., Борһанова Р.Г. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. – Казань, 2000.

Исәнбәт Н. Балалар фольклоры. – Казань, 1984.

Кашапова М.Ф. Иң татлы тел-туган тел. - Казань, 2004.

Кашапова М.Ф. Уйныйк әле балалар. - Казань, 2011.

Филичева Т.Б., Чевелева Н.А., Чиркина Г.В. «Нарушения речи у детей: Пособие для воспитателей дошкольных учреждений». - Москва, 1997.

Чиркина Г.В., Филичева Т.Б. «Технология логопедического обследования». - Москва, 1996.

Чиркина Г.В. «Программы дошкольных образовательных учреждений компенсирующего вида для детей с нарушениями речи». - Москва, 1993.

Юсупов Ф.Ю. Гөлбакча. - Казань, 1990.

Ягфаров Р. Татар балалар фольклоры. - Казань, 2011.

Ягфаров Р. Татар халык уеннары. - Казань, 1999.

Ягъфәров Р. Ал кирәк, гөл кирәк.– Казань, 1995.

Ягъфәров Р. Алтын кашык. – Казань, 1996.

Ягъфәров.Р. Кәҗә-мәкәрҗә. - Казань, 1994.

Интернет ресурсы.